КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 12 февраль г.Казань № 76

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2019 ел, 1 февраль, 59 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2019 ел, 1 февраль, 59 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 5 ноябрь, 1016 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «составын» сүзен «санын һәм составын» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы коллегиясе санын 16 кеше күләмендә;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы коллегиясенең тәкъдим ителгән составын.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслар министрлыгы коллегиясе составында:

коллегия составыннан Т.Р.Гыйләҗевны, Р.К.Сабировны, Ф.Ю.Хәйретдиновны чыгарырга;

коллегия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Гайнетдинова Лилия Әхәт кызын | Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе җитәкчесе вазыйфаларын башкаручыны (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин Илнур Ирек улын | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры урынбасарын. |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин